Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАРЛИАРЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САРМАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Школьная, д.57, д. Шарлиарема
423372
Телефон: 4-57-55

Татарстан Республикасы
САРМАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 57 йорт, Шәрләрәмә авылы,
423372
Телефон: 4-57-55

ОГРН 1061687002519 ИНН/КПП 1636005454/163601001 ОКАТО 92253882000

# КАРАР

№ 11 2018 елның 31 августы

**2018 - 2020 елларга Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнары арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча чаралар планын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданлыгы турында» 2002 елның 31 маендагы 62-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны миграцион исәпкә алу турында» 2006 елның 18 июлендәге 109-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Сарман муниципаль районының 2018 елның 20 августындагы террорчылыкка каршы комиссиясе беркетмәсе таләпләрен үтәү өчен карар бирәм:

1. 2018 - 2020 елларга Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнары арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча чаралар планын кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе: Н.Н.Хуҗина

| | | |
|---|---|---|
| Килештерелде<br>Татарстан Республикасы Сарман районында Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы урынбасары вазыйфаларын вакытлыча башкаручы<br>полиция подполковнигы<br>И.И. Латыйпов | Килештерелде<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Сарман районы буенча миграция мәсьәләләре бүлеге начальнигы<br>_________А.Ә. Миңнәхмәтов | Раслыйм<br>Сарман муниципаль районының Шәрләрәмә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе<br>___________ _ Н.Н.Хуҗина |

**2018-2020 елларга Шәрләрәмә авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнары арасында хокук бозуларны профилактикалау мәсьәләләре буенча чаралар планы**

| № п\п | Чараның атамасы | Үтәү срогы | Чаралар үткәрү өчен җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Хезмәт җитәкчеләре катнашында җирлек башкарма комитетында уздырыла торган киңәшмәләрдә миграция законнарын үтәү буенча профилактик эшләрнең торышы турындагы сорауларны карау | ай саен | Башкарма комитет секретаре, полициянең участок уполномоченные |
| 1 | Авыл советы территориясендә миграция хәленә мониторинг ясау һәм аны тотрыкландыру буенча тәкъдимнәр әзерләү | 2018-2020 еллар | Җирлекнең башкарма комитеты |
| 2 | Россия Федерациясе территориясендә яшәү урыннарына комплекслы тикшерүләр үткәрү, шулай ук алар ягыннан хокук бозуларны һәм җинаятьләрне профилактикалау һәм кисәтү | 2018-2020 еллар | Җирлек депутатлары, РИК, полициянең участок уполномоченные |
| 3 | Предприятиеләр, оешмалар һәм индивидуаль эшкуарлар тарафыннан тиешле рөхсәттән башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы законсыз мигрантларны һәм чит ил гражданнарын файдалану фактларын ачыклау һәм бетерү чараларын үткәрергә | 2018-2020 еллар | Җирлек депутатлары, РИК, полициянең участок уполномоченные |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Гражданнарның җыелышларында, шәхси сөйләшүләрдә халыкны уяу булырга, җирле үзидарә органнарына, авыл җирлеге территориясенә шикле гражданнар килү турында мәгълүмат җиткерү зарурилыгы турында хокук саклау органнарына хәбәр итәргә чакырырга | 2018-2020 еллар | Җирлек депутатлары, РИК, полициянең участок уполномоченные |
| 5 | Авыл җирлеге территориясендә вакытлыча яисә даими яшәүче чит ил гражданнарын исәпкә алу буенча белешмәләрнең актуаль банкын төзергә | 2018 ел | Җирлекнең башкарма комитеты |
| 6 | Торак фондын эксплуатацияләүне һәм аның эчтәлеген тикшереп торуны тәэмин итәргә. Торак йортларны реконструкцияләүче буш корылмаларны инвентарьлаштыруны гамәлгә ашыру, аларда чит ил гражданнарының үтеп керү һәм яшәү мөмкинлеген юкка чыгару чаралары күрү | 2018-2020 еллар | Җирлекнең башкарма комитеты |
| 7 | Федераль миграция хезмәте органнарына авыл җирлеге территориясендә чит ил гражданнарының килүе турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итүне тәэмин итәргә | 2018-2020 еллар | Җирлекнең башкарма комитеты |